**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№6** **31.10.2025**

**«Җир салымы турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 143 номерлы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлеге нигезендә, шулай ук Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Җир салымы турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 143 номерлы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына (11.09.2015 ел № 180, 25.09.2017 ел №85, 23.03.2018 ел № 103, 10.12.2020 ел № 17, 27.08.2025 ел №175 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 4 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4.2.3, 4.2.4 пунктчалары белән тулыландырырга:

«4.2.3. сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона резидентларына - махсус икътисадый зона территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренә карата Россия Федерациясе Салым кодексының 395 статьясындагы 9 пункты тарафыннан бирелгән ташламалар тәмамланганнан соң килүче айдан биш елга;

4.2.4. сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона идарәче компанияләренә - махсус икътисадый зона территориясендә урнашкан идарәче компаниянең җир кишәрлекләренә карата Татарстан Республикасында Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлү чорыннан соң килүче айдан ун елга.»

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта һәм салым чорының 1 нче санынннан да иртәрәк булмаган вакытта

3. Әлеге карарны җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе, Иске Маврин**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.Г. Нургалеев**